РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
Салманского сельского поселения Алькеевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Салман авыл җирлеге СОВЕТЫ

Адрес: 422874, Республика Татарстан, Алькеевский район, с. Салманы, ул. Молодёжная, д.12.
тел: 8 (84346) 72-2-38

Адресы: 422874, Татарстан Республикасы, Әлки районы, Салман авылы, Яшьләр ур., 12.
тел.: 8 (84346) 72-2-38

**РЕШЕНИЕ** Салман авылы **КАРАР**

№47

2023 елның 22 марты

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге Советының 2015 елның 17 февралендәге «Әлки муниципаль районының Салман авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматка ирешүне тәэмин итү хакында» 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2022 елның 14 июлендәге «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 270-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге Советы Карар итте:

1.Әлки муниципаль районының Салман авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматка ирешүне тәэмин итү хакындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 бүлекнең 10 пунктында «Интернет» челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга;

14 бүлекнең 1 абзацында «һәм җирле үзидарә органнары» сүзләрен «, җирле үзидарә органнары һәм аңа буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга, «хезмәткәрләр,» сүзләреннән соң «ведомство буйсынуындагы оешма хезмәткәрләре,» сүзләренә алмаштырырга.

9 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт өстәргә:

«1.1. Җирле үзидарә органнары һәм аларга буйсынучы оешмалар "Интернет" челтәрендә үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми битләр ачалар. Ведомство карамагындагы оешмалар дәүләт органнары һәм мондый оешмалар карамагында булган җирле үзидарә

органнары белән килешү буенча аларның эшчәнлек өлкәсе үзенчәлекләрен исәпкә алып, "Интернет" челтәрендә үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми битләр булдырмаска мөмкин. «Интернет» челтәрендәге әлеге битләрнең күрсәткечләрен күрсәтеп, рәсми битләр турында мәгълүмат тиешле дәүләт органының, җирле үзидарә органының яисә ведомство буйсынуындагы оешманың рәсми сайтында урнаштырыла.»;

9 бүлекнең 3 пунктында «1 пунктында» сүзләрен «әлеге бүлекнең 1 һәм 1.1 пунктында» сүзләренә алмаштырырга, «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләрен өстәргә;

9 бүлекнең 2 пунктында «1 пунктында» сүзләрен «әлеге бүлекнең 1 һәм 1.1 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

7 бүлекнең 1 пунктында «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләрен өстәргә;

2. Әлки муниципаль районының «Интернет» челтәрендә урнаштырыла торган Салман авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 нче кушымта

беренче абзацта «Интернет» челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга;

3. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Әлки муниципаль районы
Салман авыл җирлеге
Совет рәисе урынбасары — Д.Н.Нурутдинов

СОВЕТ САЛМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ